СОВЕТ УРМАНЧЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Ленина, д.5, п.Зверосовхоза,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422186

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРМАНЧЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Ленин ур., 5 нче йорт, Җәнлек совхозы поселогы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422186

тел.(факс): (85563) 2-12-50; e-mail: Urman.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Решение** **Карар**

№3-36 от 19 июля 2024 г

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Советының 2023 елның 13 июнендәге 5-24 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы, «Региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»2024 елның 12 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы “Урманчы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Советы **карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Советының 2023 елның 13 июнендәге «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 5-24 номерлы карарына (алаг таба-карар) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 5 пунктчаны өстәргә:

«5) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларның 2024 елның 1 гыйнварына 500 сумнан артмаган бурычы булу.».

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Мамадыш муниципаль районы
Урманчы авыл җирлеге башлыгы,
Урманчы авыл җирлеге Советы рәисе / А.Я.Ильин /